**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда. Тел. 3-28-70

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» март 2026 ел № 2

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2025 елның 22 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары һәм бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2025 елның 10 июнендәге 70н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2026 елның 29 гыйнварындагы 02-08-03-2026/Прдп35-26 номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2025 елның 22 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланганТатарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары һәм бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемлектән бюджет классификациясенең түбәндәге кодларын төшереп калдырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 904 | 1 08 04020 01 0000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 904 | 1 08 04020 01 4000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 904 | 1 08 07175 01 1000 110 | Авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы |
| 904 | 1 08 07175 01 4000 110 | Авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы |

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы: Хөснетдинов Р.Р.